**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, с.Базарные Матаки,
ул. С.Крайнова, д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С. Крайнов ур., 58

Телефон: (84346) 20-0-26, 21-0-48, факс: (84346) 21-7-57. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: alkeevskiy.tatarstan.ru.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Базарлы Матак ав.

2025 елның 16 октябреннән № 12

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 17.11.2016 елның 63-нче карарына "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә хакында" үзгәрешләр кертү турында

2025 елның 03 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексына «Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына Муниципаль хезмәт буенча үзгәреш кертү хакында» үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы **КАРАР КАБУЛ ИТӘ:**

1. 17.11.2016 елның 63-нче номерлы Совет карарына «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә хакында» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3.2 подпунктының 2 нче абзацы 2.3 пунктыннан 2 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу – вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфалардан тыш; югары белем яки урта һөнәри белем булу – авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен.».

1.2. 2.3.2 подпунктының 3 абзацы 2.3 пунктыннан 2 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә

«2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы».

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль
районы Башлыгы

СОВЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ

А.Ф. Никошин